**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 29 июлендәге 3135 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының кайбер карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында**

Шулар нигезендә Казан шәһәре икътисадының тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча төп чаралар планы расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 19 апрелендәге 922-р номерлы һәм 2022 елның 28 февралендәге 387-р номерлы боерыклары гамәлдән чыгу сәбәпле, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 15 мартындагы 755 номерлы «Казан шәһәре территориясендә икътисадның тотрыклы үсешен тәэмин итү турында»гы, 2023 елның 22 февралендәге 579 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 15 мартындагы 755 номерлы «Казан шәһәре территориясендә икътисадның тотрыклы үсешен тәэмин итү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы, 2023 елның 7 февралендәге 379 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 15 мартындагы 755 номерлы «Казан шәһәре территориясендә икътисадның тотрыклы үсешен тәэмин итү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы, 2022 елның 5 маендагы 1321 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 15 мартындагы 755 номерлы «Казан шәһәре территориясендә икътисадның тотрыклы үсешен тәэмин итү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карарларын гамәлдән чыккан дип танырга.
2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.http://www.pravo.tatarstan.ru
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**